# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 17 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Сөлек авылында урам утларын карап тору(лампочкалар сатып алу һәм урнаштыру)
- Сөлек зиратын эйләндереп алу очен профнастил сатып алу;
- Сөлек авылында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау, төзеклеген тәэмин итү(юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу,запас частьлар сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү.

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина